**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**31 гыйнвар, 2022 ел** **№ 143**

**Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә Муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 12 ноябрендәге 125 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә Муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 12 ноябрендәге 125 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Биектау муниципаль районы территориясендә Муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәнең «Вәкаләтле орган карарларына, вәкаләтле органның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү» 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган карарларына, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

4.2. Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле орган карарына, вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый.

2. Биектау муниципаль районы территориясендә Муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә «Индикатив күрсәткечләр» дип аталган 2 нче кушымтасының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## 2. ИНДИКАТИВ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

Контроль эшчәнлеге мониторингы, аны анализлау, аны тормышка ашырганда барлыкка килә торган проблемаларны ачыклау һәм зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе белән һәм хезмәт, матди һәм финанс ресурслары, шулай ук контрольдә тотылучы затлар эшчәнлегенә керешү дәрәҗәсе күләмен чагыштыруны характерлый торган аларның барлыкка килү сәбәпләрен билгеләү өчен кулланыла торган күрсәткечләр

2.1 хисап чорына, уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны

2.2 хисап чорына, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүе яисә мондый параметрлардан контроль объектының тайпылуы ачыклану нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны

2.3 хисап чорына, уздырылган үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны

2.4 хисап чорына, үткәрелгән һәр КНМ төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралары саны

2.5 хисап чорына, дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны

2.6. хисап чорына, үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны

2.7 хисап чорына, игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозу ярамаганлыгы турында кисәтүләр саны

2.8 хисап чорына, алар нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны

2.9 хисап чорына, алар нәтиҗәсендә административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны

2.10 хисап чорына, контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы

2.11 хисап чорына, контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны

2.12 хисап чорына, алар буенча прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тартылган контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны

2.13 хисап чоры ахырына, исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны

2.14 хисап чоры ахырына, хәвеф-хәтәр категорияләренә, хәвеф-хәтәр категорияләренең һәркайсы буенча кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны

2.15 хисап чоры ахырына, исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны

2.16 хисап чорына, аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары уздырылган исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны

2.17 хисап чорына, аларга карата контроль (күзәтчелек) орган тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны

2.18 хисап чорына, контрольдә тотылучы затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында гаризалар саны

2.19 хисап чорына, контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) контрольдә тотылучы затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва белдерү турында аларны канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән гаризалар саны

2.20 хисап чорына, дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет рәисенең урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров